ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
30.09.2024

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
3482

Зеленодольск шәһәренең Гоголь урамындагы 45 нче күп фатирлы йорт өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның «Күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күп фатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артыграк тәнәфесләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 13 августындагы 491 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгы нигезендә, күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләренең КФЙда гомуми мөлкәтне карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карарлар кабул итмәүләре хакында Зеленодольск шәһәре территориясендәге күп фатирлы йортлар белән идарә итү субъектлары мөрәҗәгатьләренә бәйле, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күп фатирлы йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган милекчеләр өчен һәм Зеленодольск шәһәренең Гоголь урамындагы 45 нче күп фатирлы йорт өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорт милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен аена 19,69 сум/кв.м., шул исәптән торак фонды белән идарә итү – аена 4,01 сум/кв. м. итеп билгеләргә.

1.1. Әлеге түләү күләме муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләре өчен күп фатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне үз эченә алмый.

2. Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләре өчен, муниципаль торак фондының торак

урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм  наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен  торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2024 елга куллану бәяләре индексына тигез итеп 4,5% күләмендә билгеләргә.

3. Муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм  наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен,  шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү составына керүче күп фатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме күп фатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә билгеләнә.

4. Әлеге карарны 2024 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы                                         А.С. Бауэр